**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ГЛАВА**
**Сухояшского сельского поселения**
**Азнакаевского муниципального района**

ул.Школьная, д. 4-2, село Большой Сухояш, Азнакаевского муниципального района, 423325 Тел. (факс) 34-6-16

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Азнакай муниципаль районы**
**Сукаеш авыл җирлеге Советы**
**БАШЛЫГЫ**

Мәктәп урамы, 4-2, Зур Сукаеш авылы, Азнакай муниципаль районы, 423325,Тел. (факс) 34-6-16

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
от «11» ноября 2020г.

КАРАР
№ **6**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлегенең 2021 елга һәм 2022, 2023 еллар план чорына бюджеты турында» карары проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләү турында

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлегендә яшәүчеләрнең хокукларын саклау максатларында, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Сукаеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең 2021 елга һәм 2022 һәм 2023 еллар план чорына бюджет проекты турында фикер алышуда катнашу өчен ачык тыңлаулар үткәрү юлы белән, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10. 2003 ел № 131-ФЗ Федераль законның 28 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Сукаеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 20 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлеге Советының 27.03.2012 ел № 7 ( 14.02.2015 №1, 03.09.2015 №22, 04.03.2016 №6, 30.03.2018 № 6 карарлар редакциясендә) карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлегендә халык алдында тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмә белән, карар чыгарам:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлегенең 2021 елга һәм 2022, 2023 еллар план чорына бюджеты турында»гы карары проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрүне билгеләргә.

2. Халык алдында тыңлаулар үткәрүнең инициаторы булып Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлеге Башлыгы тора.

3. Билгеләргә:
- үткәрү вакыты-2020 елның 30 ноябре 16.00 сәгатьтә;
- үткәрү урыны- Зур Сукаеш авыл мәдәният йорты;
- тикшерелә торган мәсьәлә буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр бирелә торган адрес: Зур Сукаеш авылы, Мәктәп урам, 4-2 йорт.

4. Гамәлдәге законнар, Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлегенең норматив хокукый актлары нигезендә һәм әлеге карарда билгеләнгән срокларда, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлегенең норматив хокукый актлары һәм әлеге карар белән билгеләнгән срокларда, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлеге башкарма комитетына Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлегенең 2021 елга һәм 2022,

2023 еллар план чорына бюджеты турында» карары проекты буенча ачык тыңлауларны әзерләргә һәм үткәрергә.

5.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлеге мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://pravo.tatarstan.ru Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http//aznakayevo.tatarstan.ru.) 2020 елның 11 ноябреннән дә соңга калмыйча урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымнан калдырам.

Башлык Закирова З.Җ.